ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№16 Әбсәләм авылы 29.12.2020 ел

**2020 елның 21 октябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы 8 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2020 елның 21 октябрендәге 8 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә» карарын 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы законга, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законга туры китерү, 2019 елның 17 июлендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 8 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 2020 елның 21 октябрендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 8 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында»гы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «4) хезмәт кенәгәсен, һәм(яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш» 02.03.2007 ел, № 25-ФЗ «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 маддәсендәге 3 өлешенең 4 бүлеге нигезендә (2020 елның 11 августыннан гамәлгә кертелгән 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ санлы Федераль закон белән гамәлгә кертелгән редакциясендә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш.»;

1.2. «мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы Федераль законның 16 маддәсендәге 3 өлешенең 6 пункты (2020 елның 19 июнендәге 181-

ФЗ санлы Федераль закон белән гамәлгә кертелгән редакциясендә) 4.1.3 бүлегенең 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.3. «4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару» Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсендәге 4 бүлеге нигезендә (2020 елның 11 августындагы 268-ФЗ санлы федераль закон белән гамәлгә кертелгән редакциясендә) 8.1.1 бүлекнең 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга мөмкин: http://jutaza.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы** **Г.В.Кубашева**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
СОВЕТ АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН